Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

18.11.2025 ел №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 7 ноябрендәге 5 нче номерлы карары, гражданнар җыенының 2025 елның 18 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә: сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 48 катнашучы кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 32 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «хуплый» позициясе өчен гражданнар җыенында 32катнашучы тавыш бирде, «каршы» позициясе өчен 0 тавыш. Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында гражданнар җыенын узган дип таныйрга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга

2. “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Карманково авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләргә. I-II төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына срок хезмәткә чакырылган гражданнарны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип таныйрга.

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү, үләннәр чабу,);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту)».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында

http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Иске Гришкино авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары реестрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы ____________ К.И.Алексеев
(имза) (имзаны киңәйтү)